Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге Башлыгы

# КАРАРЫ

7 ноябрь, 2024 ел № 5

Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Шихазда авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге уставының 24.1 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 19 ноябрендәге 146 номерлы (2021 елның 17 декабрендәге 34 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Питрәч авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Питрәч авыл җирлеге Шихазда авылында гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- Гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 23 ноябрендә 10 сәгатьтә Үзәк урам буенча авыл клубы бинасында, 51 й. уздырырга. Җыенда катнашучылар исемлегенә Үзәк урам буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- Гражданнар җыенының икенче этабы 2024 елның 23 ноябрендә 12 сәгатьтә Үзәк урам буенча авыл клубы бинасында, 51 й. уздырырга. Җыенда катнашучылар исемлегенә Нагорный, Шоссейная урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Питрәч авыл җирлеге Шихазда торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 төркем инвалидлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 2500 сум күләмендә үзара салым кертү  һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Питрәч авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Сөләйманов